| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>УДМУРТСКО-ТАШЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>УДМУРТ ТАШЛЫСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

16.12. 2019 г          с .Алексеевка          № 127

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен Баулы муниципаль районы Удмурт Ташлы авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында" 2007 ел, 7 нче июль, 265 нче номерлы карары

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясы нигезендә Удмурт Ташлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Удмурт Ташлы авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар Баулы муниципаль районы бюджетына төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә (алга таба – башка бюджетара трансфертлар). Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары Баулы муниципаль районы Удмурт Ташлы авыл җирлеге башкарма комитетының норматив-хокукый актлары белән (алга таба авыл җирлеге башкарма комитеты) билгеләнә.

2. Башка бюджетара трансфертлар бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге максатларга «Удмурт Ташлы авыл җирлеге бюджеты турында» Удмурт-Ташлы авыл җирлеге Советы карарында каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче-авыл җирлеге башкарма комитеты .

4. Баулы муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертларны бүлү Удмурт Ташлы авыл җирлеге Советының «тиешле финанс елына һәм план чорына» Удмурт Ташлы авыл җирлеге бюджеты турында»гы карары белән раслана.

5. Башка бюджетара трансфертларның максатлары һәм тәртибе авыл җирлеге башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты арасында төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

б) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары;

в) башка бюджетара трансфертлар бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) башка бюджетара трансфертларны күчерү графигы;

д) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан башкарыла .

8. Килешү проекты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан район башкарма комитетына җибәрелә.

9. Килешү авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе һәм район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Район бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме, муниципаль берәмлекне сайлап алу критерийлары һәм шартлары авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив-хокукый актында билгеләнә .

11. Башка бюджетара трансфертлар Баулы муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен килешүдә билгеләнгән срокларда ачылган территориаль органнары счетларына күчерелә.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Удмурт Ташлы авыл җирлеге бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13. Бирелгән елдан соң файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә Удмурт Ташлы авыл җирлеге бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш.

14. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын закон нигезендә авыл җирлеге башкарма комитеты һәм районның финанс-бюджет палатасы контрольдә тота

Глава, Председатель
Совета сельского поселения                    Дегтярев Н.С..